ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** ***Карар***

22.04.2019 Чистай шәһәре №207

Җир участогыннан файдалануның
шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәтләр
күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 2003елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 нче номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карарына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 12 декабрендә кабул ителгән 1015нче карары белән расланган җир участогыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Регламентның 3.5.2. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар йомгаклары турындагы нәтиҗә нигезендә комиссия файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы яки шундый карар кабул итүдән баш тарту (кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп) турында тәкъдим әзерли һәм аларны җирле хакимият башлыгына җибәрә”.

1.2. Регламентның 5.1. пунктының 1 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны теркәү срогын бозу, сорау 27.07. 2010 елда кабул ителгән 210 нчы номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән”.

1.3. Регламентның 5.4. пунктның 1 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 27.07. 2010 елда кабул ителгән 210 нчы номерлы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә ( гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә.”;

1.4 Регламентның 5.7. пунктның 1 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

“1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү формасында, гариза бирүчегә акчаны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган булса”.

2. “Шәһәр төзелеше һәм инфраструктура үсеше” МБУнә әлеге карарны ТРның хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов